***Казан шәһәре Мәскәү районының***
***“94 нче гимназия”***
***гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең***
***югары квалификацион категорияле***
***туган (татар) тел һәм әдәбияты укытучысы***
***Нургалиева Гөлсинә Мидхәт кызының эш тәҗрибәсеннән***

Халкым теле-хаклык теле,
аннан башка минем илем юк;
Илен сөймәс кенә телен сөймәс,
Иле юкның гына теле юк.

Бүгенге көндә актуаль булган мәсьәләләрнең берсе – ул туган телебезне, татар телен саклап калу һәм бөтен хәзинәсе белән яшь буынга тапшыру. Бу - беренче чиратта, безнең татар теле һәм әдәбияты укытучыларының бурычы. Укытучы вазыйфасын кешеләр төрлечә аңлый. Кайберәүләр анда аерым бер предмет укыта торган кешене күрә. Ләкин бу дөрес түгел. Укытучы укучыдан шәхес ясаучы зат.

Эшемнең төп максаты - укыту һәм тәрбиянең бердәмлеге, бала шәхесенә хөрмәт белән карау, ирекне чикләмәү, үзара аңлашу, укучы белән укытучы арасында демократик, гуманлы, иҗади эш стилен булдыру.

Заман таләпләре бүгенге көндә татар телен укыту процессында зур үзгәреш сорый. Укытучыларыбыз алдында бик тә җаваплы һәм әһәмиятле бурыч тора. Беренчедән, телебезне саклап калу бурычы булса, икенчедән, балаларда телне өйрәнүгә кызыксынуны бетермәү, киресенчә, бу кызыксынуны үстерү бурычы. Ә моның өчен укытучыдан үз шәхесенә тәнкыйть күзлегеннән карау, яңалыкка омтылу, белемне өзлексез камилләштерү, укыту-тәрбия процессына иҗади якын килеп эшләү сорала. Бу укытучыдан зур һөнәри осталык, түземлелек, югары технологиялардән, мәгълүмати чаралардан хәбәрдар булуын таләп итә.

Бүгенге көндә балалар мәгълүмати технологияләр белән бик иртә таныша. Шуңа күрә укучыларымда татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту, аларның игътибарын җәлеп итү максатыннан, мин дә әлеге мәгълүмати технологияләрне үзләштерергә һәм аларны укыту процессында киң кулланырга бурычлы. Сайлаган методик темам да нәкъ менә шушы максатларны үз эченә ала: “Инновацион технологияләр кулланып, татар теле һәм татар әдәбияты дәресләрендә укучыларның иҗади активлыгын үстерү.”

Заманча технологияләр файдаланып белем бирү түбәндәге мөһим бурычларны үтәргә ярдәм итә:

- укучыда татар теле һәм әдәбиятына кызыксыну уяту;
- танып – белү активлыгын үстерү;
- укучының иҗади мөмкинлекләрен камилләштерү;
- белемнәрне тирәнәйтү.


Тема өстендә эшләү укытучыдан зур җаваплылык таләп итә. Үз дәресләремдә мин балалар белән бер дулкында булырга тырышам. Мин шуны истә тотам: кинәт минем ялгыш әйтелгән сүзем яки очраклы рәвештә дөрес ясалмаган адымым балаларга сеңеп бара. Укытучы буларак мин үз укучыларым алдында үрнәк булырга тиеш, шуңа күрә мин бертуктаусыз камилләшүем өстендә эшлим. Укучыларым кызыксынып, дәртләнеп минем дәресләремә ашыга икән, мин дә бик шатланам, алар янына рәхәтләнеп барам һәм укучыларым белән очрашуны зарыгып көтәм.

Минемчә, үз эшеңне , балаларны яратудан тыш, һөнәри күнекмәләрне аеруча алдан күрә белү, сиземләү, тоемлау сәләтенә ия булу – укытучы эшендә гаять мөһим. Дәреслек материалын укып класска җиткерү авыр түгел, ләкин укытучы сүзе, материал укучы күңелендә озак вакытлар саклансын өчен, безгә, укытучыларга, иҗади эзләнү, төрле принциплар куллану иреге бирелгән. Рус мәктәбендә татар теле укыту методикасы принциплары шулай ук дидактиканың гомуми принципларыннан килеп чыга, әмма рус балаларына татар теле үзенчәлекләрен истә тотып эшләнә. Мин үз эшемне түбәндәге принципларга нигезләп алып барам:

- Фәннилек принцибының кулланыш даирәсе ап-ачык: өйрәнә торган мәгълүматлар лингвистика фәне таләпләренә туры килергә тиеш.
- Укуда аңлылык дигәндә, материалны аңлап үзләштерүне һәм гамәлдә аңлап куллануны күздә тотарга кирәк.
- Татар теле өйрәтүнең проблемалылыгы принцибы укучыларда танып белү сәләте һәм өйрәнә торган тел белән кызыксыну уята. Балалар мөстәкыйль рәвештә яңа белем үзләштерергә өйрәнергә тиешләр. Бу уңайдан укытучының роле тагын да арта. “Укытуны шундый итеп оештырырга кирәк ки, балалар мөмкин кадәр мөстәкыйль хезмәт куйсыннар, ә укытучы, шул мөстәкыйль хезмәткә җитәкчелек итеп, аңа материал биреп торсын,” – ди К.Д.Ушинский укытуның проблемалылыгы принцибы турында.
- Телне өйрәнүдә гамәли юнәлеш. Рус мәктәбендә татар теле өйрәтү- иң әүвәл аралашу чарасына өйрәтү. Бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресләрен еш үткәрәм, дәресләрдә рәсем-картиналар буенча эшлибез, укучылар ситуатив диалог һәм монолог төзиләр, дәресләрдә әңгәмәләр оештырам. Биредә В.Г. Белинский сүзләре искә төшә: ”Укучыны сүз сөйләргә һәм авырсынмыйча фикер йөртергә өйрәткәндә, аз гына теория һәм бик күп практика кирәк.”
- Укучыларның туган теле үзенчәлекләрен исәпкә алу принцибы. Рус мәктәпләрендә татар телен өйрәнгәндә ана теле хасиятләре истә тотылырга тиеш, чөнки туган тел кагыйдәләрен белү – теләсә нинди икенче бер телне өйрәнүне җиңеләйтә торган шарт ул.

Мәктәп елларында баланың икенче телне өйрәнү мөмкинлекләре гаять зур. Укучыларның татар телен өйрәнүгә кызыксыну дәрәҗәсен билгеләү максаты белән сораштыру үткәрдем. Аның нәтиҗәләре буенча 3 категория ачыкланды: түбән, уртача, югары кызыксынучанлык. Укучыларның 98% ы татар телен кызыксынып өйрәнә. Балаларның татар телен өйрәнү теләген киметмәс өчен, тәрбияле, белемле, көндәшлеккә сәләтле укучы тәрбияләү,

сыйфатлы белем бирү максатыннан, мин эшемдә төрле укыту технологияләрен кулланам.




Иҗади актив шәхес тәрбияләү - мәңгелек эшчәнлектә катлаулы проблема булып тора. Иҗади активлык үзеннән үзе генә барлыкка килми. Кеше актив эшчәнлек ихтыяҗына мохтаҗ булып туа, әмма генетик яктан нигезләнгән сәләт бары тик белем һәм тәрбиянең уңай шартларында гына киң үсешкә ирешә ала. Бу бүгенге уку-укыту системасына ФДБСның да төп таләбе булып тора.

Педагогик технологияләр — укытучы эшчәнлегенең билгеле бер эзлеклелектә оештыру һәм фаразланган нәтиҗәгә ирешү юлларын билгеләү ул.

Үстерелешле укыту технологиясенә нигезләнеп үткәрелгән дәресләр төркемнәрдә фикерләшеп эшләү, укучы-укытучы мөнәсәбәтенең демократик стильдә булуы, башкарган эшенә үзконтроль ясавы, үзбәя куюы белән кызыклы. Ул укучыларны пассив тыңлаучыдан үз эшчәнлеге белән актив идарә итүчегә әйләндерә.

Коммуникатив үстерелешле технология дәресләремдә кулланыла торган иң уңышлы технологияләрнең берсе. Коммуникатив технологиянең иң югары өстенлеге - укыту процессында сөйләм материалын барлык балаларның да үзләштерә алуы өчен шартлар тудыру.

Белгәнебезчә, балаларның үзләштерү сәләте төрлечә. Шуңа күрә, мин дәресләремдә дифференциаль алымын кулланырга яратам. Мондый алым

укучыларга шәхес итеп карарга кирәклеген тагын бер тапкыр исбатлый. Сыйныфтагы укучыларны шартлы рәвештә өч төркемгә бүләм: югары, уртача, түбән әзерлекле укучылар. Моны, әлбәттә, укучылар белергә тиеш түгел. Ул бүленеш укытучының үзе өчен генә. Шул мәгълүматлар нигезендә түбән әзерлекле  укучыларны уртачалар дәрәҗәсенә, уртачаларны исә яхшы әзерлеклеләр югарылыгына күтәрүне бурыч итеп куям. Иң элек ,әлбәттә, түбән дәрәҗәдәге дип саналган укучыларның активлыгын күтәрергә. Үзләренә бирелгән биремнәрне ахыргача кадәр үтәп чыгуларына ирешергә тырышам. Бу исә аларда үз көчләренә ышаныч тудыра. Дәреснең актуальләштерү өлешен аларга сорау  бирү белән башлыйм, ягъни бу укучыларга җиңелрәк сораулар, гадиерәк эшләр бирәм, аннан уртача әзерлекле балалардан мисаллар, дәлилләр таптырам, ә көчле укучылар нәтиҗә, йомгак ясый,тулыландыра. Шулай эшләү дәрестә һәр укучының катнашуына китерә

Туган тел һәм әдәбият укытучысы буларак, татар телен өйрәнүгә кызыксынуны арттыру максатыннан дәрес һәм дәрестән тыш эшчәнлектә инновацион технологияләр кулланып эшлим. Бу исә укучыларның иҗади активлыгын үстерүгә дә ярдәм итә.

Белем бирүдә федераль дәүләт стандарты озак еллар дәвамында сыналган һәм танылган үстерешле укыту системасы казанышларына таянып эшләнде. Шуңа күрә дә барлык инновацион технологияләр арасында мине иҗади үсеш технологиясе үзенә аеруча җәлеп итә.

Информацион технологияләр дөньясында яңалыклар белән кызыксыну теләге уятуда компьютер технологияләрен куллану бик отышлы.Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә информацион технологияләрне кулланунының өстенлекле яклары күп: дәрес материалы югары күрсәтмәле дәрәҗәдә була, укучының шәхси сыйфатын ачыкларга мөмкинлек бар, контроль һәм үзконтроль дәрәҗәсе югары, төрле дәресләрнең үзара бәйләнешен булдыру, дәрес укыту формаларын һәм ысулларын төрләндерү дәрес эчтәлеген баерак һәм кызыклырак итә.

Шулай ук информацион-коммуникатив технологияләр дә татар телен аралашу чарасы буларак өйрәнүче төркемнәр белән эшләгәндә аеруча нәтиҗәле. Монолог, диалог төзү мини-төркемнәрдә оештырыла, зур төркемнәрдә аерым бер темага фикер алышу, ситуатив күнегүләр башкарыла.

Педагогик эшчәнлегемдә электрон белем ресурсларына еш мөрәҗәгать итәм. Чирек ахырында өйрәнелгән темага берәр кечерәк текст тыңланыла һәм “Аудирование” буенча нәтиҗә ясала. Дәресләрдә интернет челтәре безгә укучылар белән шулай ук төрле музейларга “виртуаль экскурсияләр” оештырырга да ярдәм итә. Татар теле дәресендә интернет ярдәмендә уку, язу күнекмәләрен булдыру һәм үстерү, кирәкле  материал табу, укучыларның сүзлек запасын баету,  татар телен өйрәнүгә мотив формалаштыру кебек дидактик бурычларны үтәргә мөмкин. Укучылар дистанцион үткәрелә торган тестларда, викториналарда, конкурсларда, олимпиадаларда катнаша, яшьтәшләре белән аралаша алалар.

Проект технологияләре кулланылган дәресләр укучылардан аеруча да иҗади активлык таләп итә. Монда төрле фәннәрдән һәм тормыштан алынган белемнәр ярдәмгә килә. Мәсәлән, “Туган ягым”, “Татар халык ашлары”, “Герой-шагыйрь эзләреннән” темалары буенча проект-дәресләр, “Минем гаиләм” темасына гаилә белән берлектә төзелгән проектларда укучыларның буыннар бәйләнеше дә чагыла.

Дәресләр кызыклы үтсен өчен, яңа материалны аңлатканда һәм ныгытканда, сөйләм телен үстергәндә уен технологиясен дә кулланам. Әлеге технология балаларның иҗади сәләтен үстерә, фикерләү дәрәҗәсен арттыра, дәресне җанландыра, кызыклы итә. Уйный-уйный белем алганда, телдән үзләштерә торган материал җиңел ныгытыла һәм мавыктыргыч була, балаларның күзәтүчәнлеге арта. Тик әлеге эш төрен оештырганда, мин укучыларның яшь үзенчәлеген истә тотып, аны дәрестә урынлы кулланырга тырышам. Уеннарда шулай ук күрсәтмәлелек файдалану (киемнәр, уенчыклар, муляжлар, маскалар) яхшы нәтиҗә бирә. Аларны кулланып, кибеттә әйберләр алу, бүлмәне җиһазлау, өстәл әзерләү турында сөйләшергә,

киңәшләшергә мөмкин. Рольле уеннарның ситуацияләрен укучылар үзләре дә тәкъдим итә. Иң кызык уеннарның берсе — курчак театры оештыру, күренешләр сәхнәләштерү. Сәхнәләштерелгән уеннар иҗади хыялны, уйлау сәләтен үстерә. Алар уку эшен җанландыра, төрләндерә, сөйләм телен үстерүгә уңай йогынты ясый.


Укучылар үзләре эзләнсә, проектлаштырса, конструкторлаштырса, алган белемнәренә тормышта кулланылыш тапса, ягъни дөньяны үзләре танып белсәләр генә, белем алу кызыклы, мавыктыргыч һәм нәтиҗәле була. Шул максаттан, мин дәресләрдә һәм дәрестән тыш эшчәнлектә кейс технологиясен кулланам. Кейс – тормыштан алынган хәл; мәгълүматны кабул итү, конфликтны һәм проблеманы чишү. Билгеле бер проблемалы ситуацияләрне анализлау, күнекмәләрне камилләштерү, төрле өлкәләрдә тәҗрибә туплауны конкрет бер ситуациядә бирелгән проблеманы тану, күрә белү, аны чишү юлларын билгеләү, анализлау һәм нәтиҗә чыгаруны үз эченә ала; алган белемнәрне тормышта куллану, тормышта кабул иткән мәсьәләгә җаваплы карау, белем алу теләге уяту, мәгълүмат белән эшли белү, фикереңне үстерү, төркемнәрдә эшләү, үз фикереңне әйтү, дәлилли белү күнекмәләрен камилләштерә.

Методның асылы – укучыларны катлаулы проблемаларны чишәргә өйрәтү, танып белү активлыгын арттыру, аралашу сәләтен үстерү. Методның төп максаты – һәр укучыга үзенә кирәк булган белем алуның шәхси уникаль юлларын билгеләргә ярдәм итү. Укучыларның үзлегеннән белем алуга чыгу юлы күзәтелә һәм бу юл бүгенге белем алу таләпләренә туры килә.


Укытуда яңа алымнар, яңа технологияләр файдалану минем дә укытучы буларак белем дәрәҗәсен камилләштерү өчен этәргеч булды. Яңа технологияләр ярдәмендә туган телне өйрәнү укучыларны тагын да активлаштыруына, мөстәкыйльлек тәрбияләвенә инандым.

Эшемнең нәтиҗәсе түбәндәге күрсәткечләрдә чагыла (Кушымта №1):

**Татар теле**




**Татар әдәбияты**




Укыту һәм тәрбиянең төп чарасы – дәрес. Ләкин эшеңнең нәтиҗәсе, сыйфаты югары булсын өчен, дәрес белән генә чикләнеп калырга ярамый. Укучылар белән экскурсияләр оештырырга, олимпиада һәм конференцияләрдә катнашырга, укучыларның иҗади эшләү сәләтен дә үстерергә кирәк, минемчә.

| **Фән** | **Дәрәҗә (мәктәп,район,шәһәр,республика,** | **Нәтиҗә** | **Үткәрү вакыты** |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **федераль, халыкара)** | | |
| Татар теле | Республика олимпиадасының муниципаль этабы | Призёр | 2014 ел |
| Татар теле | 1-7 сыйныф укучылары өчен “Эрудит” Республика олимпиадасы | Призёр | 2017 ел |
| Уку | Кече яшьтәге мәктәп укучылары өчен “Мин кулыма китап алам” Республика олимпиадасы | Призёр | 2018 ел |
| Татар теле | 2-7 сыйныф укучылары өчен “Эрудит” Республика олимпиадасы | Җиңүче | 2018 ел |
| Татар теле | 2-7 сыйныф укучылары өчен “Эрудит” Республика олимпиадасы | Призёр | 2019 ел |
| Татар теле | II Республика олимпиадасы “Без булдырабыз!” | Җиңүче<br>Призёр | 2019 ел |

| **Чара исеме** | **Дәрәҗә (мәктәп,район,шәһәр,республика, федераль, халыкара)** | **Нәтиҗә** | **Үткәрү вакыты** |
|---|---|---|---|
| «Казан сандугачы» конкурсы | шәһәр | III урын | 2018 ел. |
| «Яшь диктор» конкурсы | район | II урын | 2018 ел |
| «Йөрәкләрдә,телләрдә син мәңге, Тукай» конкурсы | шәһәр | II урын | 2018 ел |
| «Зирәк тиен» уен конкурсы | регионара | I урын | 2016 ел |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Бөтенроссия татар балалар видеофестивале | Рәсәй | III урын | 2019 ел |
| “Татар егете” конкурсы | шәһәр | “Тапкыр егет” номинациясе | 2019 ел |

Туган тел һәм әдәбият дәресләрендә төрле педагогик технологияләрне кулланып, планлаштырылган нәтиҗәгә ирешәм. Мәгълүмати технологияләр аркылы төрле типтагы электрон әсбаблар, дәреслекләр, татар телле сайтлар, татарча Википедия, Кахот, Plickers һәм башка электрон кушымталар белем бирү һәм диагностика, тикшерү чарасы буларак та файдаланыла.

Заманча технологияләр куллану - шәхесне җәмгыятьтәге төрле үзгәрешләргә, тормыш сынауларына, фән нигезләрен ныклы үзләштерүгә әзерләүне күздә тота, татар телен укыту процессын тагын да нәтиҗәлерәк итә. Педагогика фәнендә укыту-тәрбия процессы сыйфатын үстерергә булышлык итүче технологияләр шактый. Укытучының бурычы – яңалыклар агымында югалып калмыйча, дөрес юнәлеш алу, укытучының һәр этабы өчен уку материалын аңлатуның иң уңышлы вариантын табу. Минем өчен ул- компьютер технологияләре элементларын уңышлы куллану дип әйтә алам. Дәресләрдә мин укучыларны мөстәкыйль эшчәнлеккә тарта алам икән, татар телен өйрәнүгә кызыксыну уятам икән – димәк, мин дөрес юлда. Балаларның эшчәнлеген активлаштыру максатында татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә инновацияле технологияләрне куллануның өстенлеге бәхәссез. Бу – чынбарлык һәм замана таләбе.

**Кушымта №1**

Эш тәҗрибәм белән уртаклашу:

1.Үткәрелгән ачык дәресләр,сыйныфтан тыш чаралар.

| № | Тема, класс (группа, курс) | Уровень (образовательное учреждение, район, город, межрегиональный, республиканский, федеральный, международный уровень) | Вид, тематика, место проведения методического мероприятия, в рамках которого проводилось открытый урок, занятие, мероприятие (заседание методического объединения, предметная неделя, семинар, конкурс и др.) |
|---|---|---|---|
| 1. | “Туган телем-иркә гөлем” 2,6 кл | Международный | Литературно-музыкальная композиция, посвящённая родному языку, для учителей и учащихся гимназии имени Святого Августина города Гримма |
| 2. | “Сыйфат темасын гомумиләштереп кабатлау” 4кл | Республиканский | Открытый урок обобщение в рамках программы стажировки заместителей директоров по учебной работе общеобразовательных организаций РТ “Система методической работы в образовательной организации в условиях реализации ФГОС ОО” |
| 3. | “Муса Джалиль – поэт-патриот” 6 кл | Международный | Интегрированный урок немецкого и татарского языков на Международной Научно-практической конференции «Роль информационных и |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | компьютерных технологий в развитии межкультурной компетенции в условиях билингвального обучения». Информационный центр ДААД в Казани при Казанском Федеральном Университете, МБОУ «Гимназия №94» |
| 4. | “И, туган тел, и, матур тел...” 4,10 кл | Международный | Литературно-музыкальная композиция, посвящённая родному языку, для учителей и учащихся гимназии имени Святого Августина города Гримма |
| 5. | “Татарский национальный праздник-Сабантуй” 9 кл | Международный | Интегрированный урок на творческом практикуме для учителей и учащихся Германии в рамках партнёрских отношений гимназии имени Святого Августина г.Гримма и гимназии № 94 |

2.Семинарларда катнашу

| № | Тема выступления | Уровень (образовательное учреждение, район, город, зональный, республиканский, федеральный, международный уровень) | Тема семинара, кем и для кого организовано, место проведения |
|---|---|---|---|
| 1. | «Саннар илендә» | Республиканский | Мастер – класс на |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Республиканском семинаре учителей татарского языка и литературы по теме «Основные аспекты преподавания татарского языка. Педагогический контроль в современном процессе преподавания» (МБОУ “СОШ №161”) |

3. Конференцияләрдә чыгыш ясау.

| № | Тема выступления | Уровень (образовательное учреждение, район, город, зональный, республиканский, федеральный, международный уровень) | Тема конференции, кем организована, для каких категорий работников образования проведена, место проведения |
|---|---|---|---|
| 1.<br><br>2. | «Муса Джалиль – неугасаемая звезда»<br><br>“Использование инновационных, компьтерных технологий на уроках тат. яз. и литературы” | Муниципальный<br><br>Международный | Выступление на научно-практической конференции «Муса Джалиль и его соратники- взгляд с XXI века»<br><br>Выступление на Международной Научно-практической конференции «Роль информационных и компьютерных технологий в развитии |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | межкультурной компетенции в условиях билингвального обучения». Информационный центр ДААД в Казани при Казанском Федеральном Университете, МБОУ «Гимназия №94» |
| 3. | «Формирование и развитие навыков устной речи через использование игровых ситуаций на уроках татарского языка» | Международный | Выступление на Международной Научно-практической конференции «Роль информационных и компьютерных технологий в развитии межкультурной компетенции в условиях билингвального обучения». Информационный центр ДААД в Казани при Казанском Федеральном Университете, МБОУ «Гимназия №94» |